РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422110, г. Кукмор, ул. Ленина,15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин, ур., 15

тел.: (8 84364) 2-62-71, факс 2-60-57; e-mail:Ispolkom.Kukmor@tatar.ru


**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы «Манзарас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү**

**1.** Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Манзарас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы» проекты (алга таба – проект) буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

**2. Проектка карата мәгълүмати материаллар исемлеге:**

- Торак пунктлар чикләре карталарының растр форматындагы күчермәләре;
- Объектларны растр форматында планлаштырып урнаштыру карталарының күчермәләре;
- Җирлекнең яисә шәһәр округының растр форматындагы функциональ зоналары карталарының күчермәләре;
- Нигезләү материалларының растр форматындагы (ГОиЧС) карта рәвешендәге күчермәләре;
- Нигезләү материалларының растр форматындагы (ЗОУИТ сущ) карта рәвешендәге күчермәләре;
- Нигезләү материалларының растр форматындагы (ЗОУИТ_проект) карта рәвешендәге күчермәләре;
- Нигезләү материалларының растр форматындагы (инженерлык инфраструктурасы) карта рәвешендәге күчермәләре;
- Нигезләү материалларының растр форматындагы (хәзерге кулланышы) карта рәвешендәге күчермәләре;
-Шәһәр төзелеше кодексының 19 ст. 3.1 п., 23 ст. 5.1 п. һәм 30 ст. 6.1 п. каралган белешмәләр;
- Текст формасындагы нигезләү материаллары (ООС һәм ГОЧС);
- Нигезләү материаллары текст формасында;
- Территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә.

**3. Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм вакыты:**

Проект буенча гавами тыңлаулар 2025 елның 31 гыйнварыннан 2025 елның 14 февраленә кадәр үткәрелә. Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;

- проектны һәм аңа карата мәгълүмати материалларны рәсми сайтка урнаштыру һәм бу проектның экспозицияләрен ачу;

- проект экспозицияләрен үткәрү;

- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү;

- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;

- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре;

- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

**5. Чикләрендә гавами тыңлаулар уздырыла торган территория**:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлеге.

**6. Проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:**

- ТР, Кукмара районы, Манзарас ав., Яшьләр ур., 18а, кадастр номеры 16:23:010503:74, Манзарас авылы Мәдәният йорты бинасы, 9.00 сәг., 31 гыйнвар, 2025 ел.

- ТР, Кукмара районы, Өлге ав., Үзәк ур., 19, кадастр номеры 16:23:010802:59, авыл клубы бинасы, 9.30 сәг., 31 гыйнвар, 2025 ел.

- ТР, Кукмара районы, Кәчимер ав., Таҗетдинов ур., 36А, КФҮ бинасы, кадастр номеры 16:23:010601:343, 10.00 сәг., 31 гыйнвар, 2025 ел.

**7. Проект экспозицияләрен үткәрү вакыты:**

31.01.2025 – 14.02.2025.

**8. Экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**

Эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш тәнәфесе – 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

**9. Гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм формасы:**

2025 елның 31 ноябреннән 2025 елның 14 февраленә кадәрге чорда Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ШтК) $5^1$ статьясының 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- рәсми сайт аша;

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының гавами тыңлауларын оештыручыга язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Кукмара шәһ., Ленина ур., 15, тел. (84364) 2-80-56 (8.00 сәг. тән 17.00 сәг. кә кадәр);

- гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабында (журналында) язып кую юлы белән, адресы: 422111, Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Манзарас авылы, Яшьләр ур. , 18а (8.00 сәг. тән 17.00 сәг. кә кадәр).

РФ ШтКның $5^1$ статьясындагы 12 өлеше нигезендә идентификация узган гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яисә телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

**10. Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 14 февралендә уздырырга:

- 17.00 сәгатьтә Манзарас авылы Мәдәният йортында, адресы: Татарстан Республикасы, Кукмара районы, Манзарас авылы, Яшьләр ур. , 18а.

**11. Проект һәм аңа карата мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**

Проект Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (kukmor.tatarstan.ru) 2025 елның 31 гыйнварыннан «Район турында Авыл җирлекләре Манзарас авыл җирлеге МБ АЖ территориаль планлаштыру документациясе бүлегендә урнаштырылачак.

**12. Әлеге хәбәрне** Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе А.Х. Гарифуллин**